ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2019ел № 6323

Муниципаль гарантияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.2 һәм 115.3 статьялары, шәһәр Уставының 41, 65, 74 статьялары, Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 17 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) муниципаль гарантияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан муниципаль гарантияләр биргәндә принципалның финанс хәлен анализлау, шулай ук муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантияләр биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибен, 2 нче кушымтада каралганча;

3) муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантияләр биргәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне гамәлгә ашыру, шулай ук муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантияләр биргәннән соң тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын контрольдә тоту тәртибен, 3 кушымтада каралганча;

4) муниципаль гарантия буенча гарантның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча принципалга йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибен, 4 нче кушымтада каралганча.

2. «Челнинские известия» газетасының 2016 елның 20 маендагы 36 номерында, 2016 елның 25 маендагы 37 номерында басылып чыккан Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 29 апрелендәге 2160 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы

рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:/pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. 2020 елның 1 гыйнварыннан әлеге карарның үз көченә керүен билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 5 декабрендәге
6323 номерлы карарына
1 нче кушымта

Муниципаль гарантияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен (алга таба – муниципаль гарантияләр) бирү тәртибен билгели.

2. Муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль гарантияләр, әлеге нигезләмә нигезендә Шәһәр Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карарында күрсәтелгән һәм бирелә торган гарантияләрнең гомуми суммасы чикләрендә Башкарма комитет тарафыннан бирелә.

3. Муниципаль гарантияләр бирү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.2 статьясының 1.1 пунктында каралган шартлар үтәлгәндә гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль гарантия бирү, шулай ук муниципаль гарантия бирү турында килешү төзү принципал һәм (яки) бенефициар тарафыннан Башкарма комитетка, яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.2 статьясының 5 пункты нигезендә җәлеп ителгән агентка, әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза һәм документларның тулы комплектын биргәннән соң гамәлгә ашырыла:

1) юридик зат өчен гамәлгә кую документлары;

2) принципал вазыйфаи затларының тиешле килешүләр төзүгә вәкаләтләрен раслаучы документларның күчермәләре;

3) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт реестрыннан алынган өземтә;

4) принципалның соңгы ел эшчәнлеге турында расланган форма буенча бухгалтерлык хисабы һәм аны кабул итү турында территориаль салым органы билгеләре белән аңлатмалы язу күчермәләре (яки аларны кабул итү турында территориаль салым органының электрон рәвештәге хәбәре белән);

5) агымдагы елның башына һәм агымдагы елның соңгы хисап чоры ахырына эрерәк дебиторлар һәм кредиторлар күрсәтелгән дебиторлык һәм кредиторлык бурычларының расшифровкасы (гомуми бурыч күләменең 5%тан артканы) һәм аны түләп бетерү сроклары;

6) принципалның хисап елындагы бухгалтерлык хисабының дөреслеге турында аудиторлык бәяләмәсенең нотариаль расланган күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә ел саен үткәрелә торган мәҗбүри аудиторлык тикшерүе үтәргә тиешле икътисадый субъектларга кагыла);

7) принципалның барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча, бурычлары булмау турында, аны тапшыру датасына 14 көннән дә алдан алынмаган салым органы белешмәләре;

8) принципалның соңгы хисап датасына һәм агымдагы елның башына чиста активлары бәясенең исәп-хисабы.

5. Муниципаль гарантия Башкарма комитет карары һәм әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль гарантия бирү турында килешү нигезендә бирелә.

6. Принципалның финанс хәлен анализлау, тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерү, муниципаль гарантияне, шулай ук муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантияләр биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглау әлеге карар нигезендә Башкарма комитетның финанс идарәсе, яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.2 статьясының 5 пункты нигезендә җәлеп ителгән агент тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль гарантия принципалның, гарантның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча андый гарантияне тулы күләмдә яки нинди дә булса өлешен үтәү сәбәпле барлыкка килә торган принципалга йөкләмәләр үтәүне тәэмин итүнең өченче заты тарафыннан бирелгән шартларда бирелә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль гарантиянең гамәлдә булу срогы дәвамында тәэмин итү составын һәм гомуми күләмен (сумнар) тәэмин итү максатында гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүнең җитәрлек булмавы ачыкланганда (шул исәптән, принципалның финанс хәле шактый начарайган очракта, принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципалның йөкләмәләрне үтәвен тәэмин итүгә банк гарантиясе яки поручительлек, залог предметының базар бәясен киметүне тәэмин итүче юридик зат), принципал тарафыннан 90 көнлек срокта тәэмин итү (тулы һәм өлешчә) яисә өстәмә (җитмәгән суммага) тәэмин итү.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль гарантияләрен
бирү тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Форма

Башкарма комитет
Җитәкчесе
__________________________

Муниципаль гарантия бирү турында
гариза

________________________________________________________________________________
(оешманың исеме, ИНН)

________________________________________________________________________________
(юридик адресы)

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантиясен бирү мөмкинлеген карауны сорый.
Гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмә: ____________________________________
Муниципаль йөкләмә белән тәэмин ителә торган йөкләмәнең күләме:
________________________________________________________________________________
(сумма цифрлар һәм сүз белән языла)
Йөкләмә кем каршында тәэмин ителә (оешманың исеме): ________________________
Гарантиянең гамәлдә булу срогы: ____________________________________________
(календарь көннәрдә)

Оешма җитәкчесе ______________/__________________________)
(имза) (Ф.И.А.и.)

М.У. «_______» _____________ ______ ел

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль гарантияләрен
бирү тәртибе турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Форма

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантиясен бирү турында
килешү №____

Яр Чаллы шәһәре «____»__________ 20___ ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән «ТР Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба «Гарант» дип атала, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче ________________________________________________ Башкарма комитет Җитәкчесе __________________________________ исеменнән, алга таба «Бенефициар» дип атала, __________________________________ һәм ____________________________________ нигезендә эш итүче __________________________________ исеменнән, алга таба «Принципал» дип атала, алга таба «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Принципал тарафыннан, ____________________ (_______________________) суммадагы кредитны, шул исәптән төп бурычны – _______________ (_____________) һәм кредиттан файдаланган өчен процентларны – _____________ (________________) сум күләмендә кире кайтару буенча Принципал һәм Бенефициар арасында төзелгән «___» _______ 20___ ел №___ Кредит килешүе (алга таба – Кредит килешүе) буенча йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, Гарант Бенефициарның язмача таләбе буенча әлеге Килешү һәм «____» ________ 20___ ел № ____ Муниципаль гарантия (алга таба – Гарантия) белән билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Россия Федерациясе валютасындагы акчалата сумманы түләүне үз өстенә ала.

1.2. Гарантның бенефициар каршындагы Гарантиядә каралган йөкләмәсе бенефициар таләбе куелган вакытта үтәлми калган һәм гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләре суммасын түләү белән чикләнә, әмма бу гарантия бирелгән суммадан артмаска тиеш.

1.3. Принципал Кредит килешүе шартлары нигезендә Бенефициарга мөнәсәбәтле Гарантия белән тәэмин ителгән акча йөкләмәләрен үтәгән саен, Гарантның Гарантия буенча йөкләмәсе тиешле суммага кими.

1.4. Гарант Принципалның штрафлар, комиссияләр, пенялар түләү турындагы йөкләмәләре үтәлешен гарантияләми.

1.5. Муниципаль гарантия принципалга карата гарантның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча андый гарантияне тулы күләмдә яки нинди дә булса өлешен үтәү сәбәпле барлыкка килә торган принципалга йөкләмәләр үтәүне тәэмин итүнең өченче заты тарафыннан бирелгән шартларда бирелә.

Принципалга карата гарантның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча принципалның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү алымы
_____________________________________________________________________________ .

## 2. Гарантның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Гарант хокуклы:

2.1.1. Гарантияне Гарантиядә күрсәтелгән нигезләр буенча гына кире алырга;

2.1.2. Гарантиядә каралган очракларда, Бенефициарга Гарантия буенча акча суммасын түләү турындагы таләбен (алга таба – Бенефициар таләбе) канәгатьләндерүдән баш тартырга;

2.1.3. Бенефициар таләбенә каршы чыгарга, Гарантия шартларында башкача каралмаган булса, бу каршылыкны Принципал тәкъдим итәргә мөмкин. Гарант, хәтта Принципал әлеге каршылыклардан баш тарткан яисә үз бурычын таныган очракта да, шушы каршылыкларга хокукын югалтмый.

2.2. Гарант бурычлы:

2.2.1. Принципалга Бенефициар таләбен алу турында хәбәр итәргә һәм барлык документлар белән бергә таләп күчермәсен аңа тапшырырга;

2.2.2. таләпнең һәм аңа теркәлгән документларның Гарантия шартларына туры килүен билгеләү өчен, барлык теркәлгән документлар белән бергә Бенефициар таләбен Гарантиядә билгеләнгән срокта карап тикшерергә;

2.2.3. Бенефициарга аның таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту турында хәбәр итәргә;

2.2.4. Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта, Гарантия буенча йөкләмәләрне Гарантиядә билгеләнгән срокта үтәргә;

2.2.5. Принципалга Гарантияне туктату турында хәбәр итәргә.

## 3. Принципалның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Моның белән Принципал әлеге Килешү буенча барлык йөкләмәләрне үтәү өчен барлык кирәкле вәкаләтләргә ия булуын раслый һәм Принципалга бернинди өстәмә рөхсәтләр һәм килешенүләр таләп ителми.

3.2. Принципал түбәндәге йөкләмәләрне ала:

3.2.1. Принципалның Кредит килешүе шартларын үтәү буенча Бенефициар каршындагы үз йөкләмәләрен үтәмәү яки әлеге Килешү шартларын бозуга китерергә мөмкин булган нинди дә булса хәл туу очраклары турында Гарантка хәбәр итәргә;

3.2.2. Гарантның соравы буенча Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, конфиденциаль буларак карала торган мәгълүматны бирергә;

3.2.3. Гарантка Бенефициар белән барлыкка килгән фикер каршылыклары турында хәбәр итәргә.

3.2.4. шәһәр бюджеты кеременә муниципаль гарантия буенча йөкләмәне үтәү өчен (өлешчә үтәү) Гарант тарафыннан регресс тәртибендә түләнгән сумманы регресс тәртибендә Гарантка Гарантның регресс тәртибендә кире кайтару турында таләп алган көннән башлап ______ эш көне эчендә кире кайтару.

## 4. Бенефициарның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Бенефициар бурычлы:

4.1.1. Гарантиядә күрсәтелгән документларны теркәп, таләпне язма рәвештә бирергә;

4.1.2. түбәндәге вакыйгалар барлыкка килгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмый, Гарантка язма рәвештә хәбәр итәргә:

- акчаны исәптән чыгару турында Принципалның исәп-хисап счеты буенча өземтәләрне, кредитлар түләү турында Принципалның ссуда счетлары буенча, шулай

ук Бенефициарның вәкаләтле затлары тарафыннан имзаланган һәм Бенефициар мөһере белән расланган процентлар түләү турында процентларны исәпләү счетлары буенча өземтәләрне, шулай ук Бенфициарга акча күчерү турында Принципалның Бенифициар билгесе куелган түләү кәгазьләре күчермәләрен теркәп, Принципал, өченче затлар тарафыннан Кредит килешүе буенча йөкләмәләрнең өлешчә яки тулысынча үтәлүе турында;

- Кредит килешүен өзү турында;

- Принципал тарафыннан Бенефициар каршындагы үз йөкләмәләренең кайсын да булса үтәмәү турында, шулай ук Принципал тарафыннан кредитор яки өченче затлар каршындагы үз йөкләмәләрен үтәмәүгә китерергә мөмкин булган барлык хәлләр турында, шул ук вакытта Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә кирәкле мәгълүмат алу өчен барлык чараларны күреп;

4.1.3. Кредит килешүенә нинди дә булса үзгәрешләр яки өстәмәләр кертүгә Гарантның язмача ризалыгын алырга һәм килешенергә.

4.2. Гарантия буенча Гарантка карата Бенефициарның таләп хокукы башка затка тапшырыла алмый.

## 5. Гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү

5.1. Принципал тарафыннан Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү срогы җиткәч, Бенефициар Гарантка таләпләр куйганчы, Принципалга карата тиешле түләүләр турында язмача таләп куярга тиеш. Әгәр Принципал 15 эш көне эчендә Бенефициар куйган таләп буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәсә, Бенефициар Гарантия буенча Гарант йөкләмәләрен үтәү турында язмача таләп белән Гарантка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.2. Бенефициар таләбе Гарантка, түбәндәге документларны теркәп, язма рәвештә бирелергә тиеш:

5.2.1. хисап көненнән соң икенче көнгә ссуда счетлары һәм Принципал процентларын исәпләү счетлары буенча өземтә;

5.2.2. срогы чыккан түләнмәгән төп бурыч күләмен һәм түләнмәгән срогы чыккан процентлар күләмен раслый торган исәпләүләр;

5.2.3. Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында Принципалга мөрәҗәгате;

5.2.4. Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында мөрәҗәгатенә Принципалның җавабы (булган очракта).

Бенфициар таләбенә теркәлгән документлар Бенефициарның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган һәм Бенефициар мөһере белән расланган булырга тиеш.

5.3. Бенефициар таләбе Гарантка кергән дата таләп куелган дата булып санала.

5.4. Гарант Бенефициарның таләбен һәм аңа теркәлгән документларны, таләп куелган көннән соң 10 эш көне эчендә карап тикшерә.

5.5. Бенефициарның гарантияне үтәү турындагы таләбе һәм аңа теркәлгән документлар нигезсез дип таныла һәм (яки) гарантия шартларына туры килми һәм гарант Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115 статьясының 16 пунктында каралган очракларда бенефициарның таләпләрен үтәүдән баш тарта.

5.6. Бенефициар таләбен нигезле дип тану кире кагылган очракта Гарант, таләп куелган көннән соң 10 көн эчендә, Бенефициарга әлеге таләпне канәгатьләндерүдән баш тарту турында нигезле хәбәр җибәрә.

5.7. Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта Гарант, Бенефициар таләбе нигезле дип танылган көннән соң 30 эш көне эчендә, Гарантия буенча йөкләмәне үти.

## 6. Гарантияне кире алу шартлары

6.1. Гарантия Гарант тарафыннан түбәндәге очракларда кире алынырга мөмкин:

6.1.1. Кредит килешүенә Гарант белән килешенмәгән һәм җаваплылыкны арттыруга яки Гарант өчен башка тискәре нәтиҗәләргә китерә торган шартлар кертелгәндә, шул исәптән кредит һәм кредит буенча процент ставкасы күләме, Кредит килешүенең гамәлдә булу срогы үзгәргән очракта;

6.1.2. Кредит килешүен өзгәндә.

## 7. Гарантиянең гамәлдәге вакытын туктату

7.1. Гарантның Гарантия буенча Бенефициар каршындагы йөкләмәләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) Гарант муниципаль гарантия белән билгеләнгән акчаларны Бенефициарга түләгәндә;

2) муниципаль гарантиянең билгеләнгән бирелү срогы чыкканда (гарантиянең гамәлдәге срогы);

3) Принципал һәм (яки) өченче затлар тарафыннан муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләре үтәлгән очракта, яисә башка нигезләрдә Принципалның әлеге йөкләмәләре туктатылганда (бенефициарның гарантка һәм (яки) судка гарантияне үтәве турында гарант таләбе күрсәтелгән булуга бәйсез рәвештә);

4) Бенефициар Гарантка кире кайтару юлы һәм (яки) Гарантны аның йөкләмәләреннән азат итү турында язмача гаризасы белән гарант Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.1 статьясында каралган Гарантия, андый Гарантия буенча бенефициарларның фактта булмау һәм киләчәктә алар барлыкка килү өчен нигезләр булмау шартларында үз хокукларыннан баш тарту нәтиҗәсендә;

5) Принципалның тәэмин итү өчен Гарантия бирелгән йөкләмәсе билгеләнгән срокта барлыкка килмәсә;

6) Принципалның төп йөкләмәсе туктатылганда (шул исәптән принципалны һәм (яки) бенефициарны, бенефициар гарантка һәм (яки) судка гарантка гарантияне үтәү турында таләп күрсәткәннән соң ликвидацияләү сәбәпле) яки аның гамәлдән чыгуы танылганда;

7) гарантның алдан бирелгән язмача ризалыгыннан башка төп йөкләмә буенча башка нигезләр буенча бенефициарга караган очракта, аның облигацияләргә хокуклары һәм (яки) йөкләмәләре (бурычы) (күрсәтелгән хокукларны (хокук һәм йөкләмәләрне) бирүдән (күчерүдән тыш) Россия Федерациясенең кыйммәтле кәгазьләр турындагы законнарында билгеләнгән тәртиптә яңа хуҗага (сатып алучыга) күчүе сәбәпле, принципалның (эмитентның) гарантия белән тәэмин итеәә торган йөкләмәләрен үтәү башка затка бирелгән яки башка затка күчерелгән очракта;

8) гарантның алдан бирелгән язмача ризалыгыннан башка төп йөкләмә буенча башка нигезләр буенча принципалга караган очракта, хокукларны һәм (яки) йөкләмәләрне (бурычны) башка затка бирү яки башка затка күчерү;

9) муниципаль гарантияне кире алу очракларында һәм муниципаль гарантиядә күрсәтелгән нигезләр буенча;

10) муниципаль гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

## 8. Гарантиянең гамәлдәге срогы

8.1. Гарантия «____» ___________ 20___ елдан үз көченә керә һәм «____» _________ 20___ елга кадәр гамәлдә була.

## 9. Бәхәсләрне хәл итү

9.1. Әлеге Килешү һәм Гарантия белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр Россия Федерациясе законнары белән җайга салына.

9.2. Яклар арасында барлыкка килгән бәхәсләр юлы белән хәл ителә.

9.3. Бәхәсле мәсьәләләр җайга салынмаган очракта Яклар, бәхәсне хәл итү өчен, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә арбитраж судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## 10. Йомгаклау нигезләмәләре

10.1. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә төзелде.

10.2. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр язма рәвештә Яклар тарафыннан кертелә.

10.3. Әлеге Килешү Гарантиянең гамәлдә булу срогына төзелде.

10.4. Әлеге Килешүнең 6.1 һәм 7.1 пунктларында каралган нигезләр буенча Гарантия кире алынган яки аның гамәлдәге вакыты туктатылган очракта, Гарантия йөкләмәсе дә туктатыла.

## 11. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

| «Гарант» | «Бенефициар» | «Принципал» |
|---|---|---|

Муниципаль гарантияләр бирү
тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Форма

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантиясе № _____

Яр Чаллы шәһәре «____»__________
20___ ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән «ТР Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба «Гарант» дип атала, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «___»_________ 20___ ел №____ карары нигезендә эш итүче Башкарма комитет Җитәкчесе _________________________________ исеменнән, йөкләмәләрнең үтәлеше өчен җавап бирүне үз өстенә ала, алга таба «Принципал» дип атала, Устав нигезендә эш итүче __________________________ исеменнән, ____________________ каршында, алга таба «Бенефициар» дип атала, ________________________ исеменнән, түбәндәге шартларда:

1. Принципал тарафыннан, ________________ (___________________) суммадагы кредитны, шул исәптән төп бурычны – _______________ (_____________) һәм кредиттан файдаланган өчен процентларны – _____________ (________________) сум күләмендә кире кайтару буенча Принципал һәм Бенефициар арасында төзелгән бирү лимиты буенча кредит линиясе ачуга «____» ________ 20___ ел №___ Килешү (алга таба – Кредит килешүе) буенча йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, Гарант Бенефициарның язмача таләбе буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына ________________ (______________) күләмендә акчалата сумманы түләүне үз өстенә ала.

2. Бенефициарның әлеге Гарантия (алга таба – Гарантия) буенча акча суммасын түләү турындагы таләбе Гарантка, түбәндәге документларны теркәп, язма рәвештә бирелергә тиеш:

1) хисап көненнән соң икенче көнгә ссуда счетлары һәм Принципал процентларын исәпләү счетлары буенча өземтә;

2) срогы чыккан түләнмәгән төп бурыч күләмен һәм түләнмәгән срогы чыккан процентлар күләмен раслый торган исәпләүләр;

3) Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында Принципалга мөрәҗәгате;

4) Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында мөрәҗәгатенә Принципалның җавабы (булган очракта).

Бенфициар таләбенә теркәлгән документлар Бенефициарның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган һәм Бенефициар мөһере белән расланган булырга тиеш.

3. Гарант Бенефициар таләбен һәм аңа теркәлгән документларны, таләп куелган көннән соң 10 эш көне эчендә карап тикшерә.

4. Бенефициарның гарантияне үтәү турында таләбе һәм аңа теркәлгән документлар нигезсез һәм (яки) гарантия шартларына туры килми дип таныла һәм

Гарант Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115 статьясының 16 пунктында каралган очракларда Бенефициар таләбен канәгатьләндерүдән баш тарта.

5. Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта Гарант, Бенефициар таләбе нигезле дип танылган көннән соң 30 эш көне эчендә, Гарантия буенча йөкләмәне үти.

6. Гарантның бенефициар каршындагы Гарантиядә каралган йөкләмәсе бенефициар таләбе куелган вакытта үтәлми калган һәм гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләре суммасын түләү белән чикләнә, әмма бу гарантия бирелгән суммадан артмаска тиеш.

Гарант Принципалның штрафлар, комиссияләр, пенялар түләү турындагы йөкләмәләре үтәлешен гарантияләми.

7. Гарантның Гарантия буенча Бенефициар каршындагы йөкләмәләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) Гарант Гарантия белән билгеләнгән сумманы Бенефициарга түләгәндә;

2) Муниципаль гарантиянең билгеләнгән бирелү срогы чыкканда (гарантиянең гамәлдәге срогы);

3) Принципал һәм (яки) өченче затлар тарафыннан муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләре үтәлгән очракта, яисә башка нигезләрдә Принципалның әлеге йөкләмәләре туктатылганда (бенефициарның гарантка һәм (яки) судка гарантияне үтәве турында гарант таләбе күрсәтелгән булуга бәйсез рәвештә);

4) Бенефициар Гарантка кире кайтару юлы һәм (яки) Гарантны аның йөкләмәләреннән азат итү турында язмача гаризасы белән гарант Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.1 статьясында каралган Гарантия, андый Гарантия буенча бенефициарларның фактта булмау һәм киләчәктә алар барлыкка килү өчен нигезләр булмау шартларында үз хокукларыннан баш тарту нәтиҗәсендә;

5) Принципалның тәэмин итү өчен Гарантия бирелгән йөкләмәсе барлыкка килмәсә;

6) Принципалның төп йөкләмәсе туктатылганда (шул исәптән принципалны һәм (яки) бенефициарны, бенефициар гарантка һәм (яки) судка гарантка гарантияне үтәү турында таләп күрсәткәннән соң ликвидацияләү сәбәпле) яки аның гамәлдән чыгуы танылганда;

7) гарантның алдан бирелгән язмача ризалыгыннан башка төп йөкләмә буенча башка нигезләр буенча бенефициарга караган очракта, аның облигацияләргә хокуклары һәм (яки) йөкләмәләре (бурычы) (күрсәтелгән хокукларны (хокук һәм йөкләмәләрне) бирүдән (күчерүдән тыш) Россия Федерациясенең кыйммәтле кәгазьләр турындагы законнарында билгеләнгән тәртиптә яңа хуҗага (сатып алучыга) күчүе сәбәпле, принципалның (эмитентның) гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмәләрен үтәү башка затка бирелгән яки башка затка күчкән очракта;

8) гарантның алдан бирелгән язмача ризалыгыннан башка төп йөкләмә буенча башка нигезләр буенча принципалга караган очракта, хокукларны һәм (яки) йөкләмәләрне (бурычны) башка затка бирү яки башка затка күчерү;

9) муниципаль гарантияне кире алу очракларында һәм муниципаль гарантиядә күрсәтелгән нигезләр буенча;

10) муниципаль гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

8. Гарантия Гарант тарафыннан түбәндәге очракларда кире алынырга мөмкин:

1) Кредит килешүенә Гарант белән килешенмәгән һәм җаваплылыкны арттыруга яки Гарант өчен башка тискәре нәтиҗәләргә китерә торган шартлар

кертелгәндә, шул исәптән кредит һәм кредит буенча процент ставкасы күләме, Кредит килешүенең гамәлдә булу срогы үзгәргән очракта;

2) Кредит килешүен өзгәндә.

9. Муниципаль гарантия принципал, өченче зат тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлүе, принципалның гарантның принципалга карата регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча андый гарантияне тулысынча яки нинди дә булса өлешен үтәү белән бәйле буларак барлыкка килгән таләпләрен үтәүне тәэмин итүе шартларында бирелә.

10. Гарантия буенча Гарантка карата Бенефициарның таләп хокукы башка затка тапшырыла алмый.

11. Гарантия «____» ___________ 20___ елдан үз көченә керә һәм «____» _________ 20___ елга кадәр гамәлдә була.

Башкарма комитет Җитәкчесе

М.У.

Башкарма комитетның
2019 елның 5 декабрендәге
6323 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль берәмлек муниципаль гарантия биргәндә
принципалның финанс хәлен анализлау, шулай ук муниципаль берәмлек
муниципаль гарантия биргәннән соң Принципалның финанс хәлен
мониторинглауны гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Әлеге тәртип муниципаль берәмлек муниципаль гарантия биргәндә принципалның финанс хәлен анализлау (алга таба – алдан анализлау), шулай ук муниципаль берәмлек муниципаль гарантия биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглауны (алга таба анализлау) гамәлгә ашыруга таләпләрне билгели.

2. Муниципаль гарантияләр бирү һәм үтәү, шул исәптән принципалның, аның поручителенең (гарантларының) финанс хәлен анализлау, принципалның, аның поручителенең, муниципаль гарантияләр бирү һәм үтәү белән бәйле барлыкка килгән башка затлар йөкләмәләренең аналитик исәбен алып бару, әлеге затларның бурычларын кайтарып алу Россия Бюджет кодексының 115.2 статьясында билгеләнгән тәртиптә финанс идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантия (алга таба – гарантия) бирелгәнче принципалның финанс хәлен алдан анализлау Башкарма комитетның финанс идарәсе (алга таба – финанс идарәсе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Принципалның финанс хәлен алга таба анализлау ел саен финанс идарәсе тарафыннан гарантия биргәннән соң, бирелгән гарантия гамәлдә булган срокта. Гарантия буенча йөкләмәләр туктатылганга кадәр гамәлгә ашырыла.

3. Принципалның финанс хәлен алдан анализлау принципал тарафыннан муниципаль гарантия алу өчен Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документлар исемлеге буенча бирелгән документларны анализлау нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Принципалның финанс хәлен алга таба анализлау принципал тарафыннан финанс идарәсенә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4 пункты нигезендә тапшырылган документлар нигезендә агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмый башкарыла:

4) принципалның барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча, бурычлары булмау турында, аны тапшыру датасына 14 көннән дә алдан алынмаган салым органы белешмәләре;

5) принципалның соңгы хисап датасына һәм агымдагы елның башына чиста активлары бәясенең исәп-хисабы.

5. Принципалның финанс хәлен бәяләү принципалның Финанс хәлен бәяләү методикасына туры китереп, әлеге тәртипкә кушымта нигезендә башкарылы.

6. Принципалның финанс хәлен алдан һәм алга таба бәяләү нәтиҗәләре буенча финанс идарәсе тарафыннан тиешле бәяләмәләр төзелә.

7. Принципалның финанс хәлен анализлау, аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү һәм бәяләмәне Башкарма комитетка тапшыру принципал Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4 пункты нигезендә документлар тапшырган көннән башлап 30 көн эчендә башкарыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Муниципаль берәмлек муниципаль гарантия биргәндә принципалның финанс хәлен анализлау, шулай ук муниципаль берәмлек муниципаль гарантия биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

## Принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы

1. Принципалның финанс хәлен бәяләү өчен, бухгалтерлык балансы мәгълүматлары һәм финанс нәтиҗәләре турында хисап нигезендә исәпләнә торган база финанс индикаторларының өч төркеме кулланыла:

1) ликвидлык коэффициенты;

2) үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты;

3) рентабельлек күрсәткече.

2. Ликвидлык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

1) абсолют ликвидлык коэффициенты;

2) тиз ликвидлык коэффициенты;

3) агымдагы ликвидлык коэффициенты.

3. Абсолют ликвидлык коэффициенты ($K_1$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_1 = \frac{ден.средства(1250) + кр.фин.вложения(1240)}{тек.обязательсва(1500 - 1530 - 1540)},$$

монда

акча (1250) - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акча (бухгалтерлык балансының юл коды 1250);

кыска сроклы финанс салулар (1240) – хисап чоры ахырына формалашкан кыска сроклы финанс салулар (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы (бухгалтерлык балансының юл коды 1240);

агымдагы йөкләмәләр (1500-1530-1540) - түләү срогы хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк булган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Зурлык V бухгалтерлык балансы бүлеге нәтиҗәсенең (бухгалтерлык балансының юл коды 1500), алдагы чор керемнәренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) һәм бәяләү йөкләмәләренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1540) аермасы буларак билгеләнә.

4. Тиз ликвидлык коэффициенты ($K_2$) акчаны хуҗалык әйләнешеннән оператив рәвештә азат итү һәм булган финанс йөкләмәләрен түләү сәләтен күрсәтә. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_2 = \frac{деб.задолженность(1230) + кр.фин.вложения(1240) + ден.средства(1250)}{тек.обязательства(1500 - 1530 - 1540)},$$

монда

дебитор бурычы (1230) - түләнүе ел дәвамында көтелә торган дебитор бурычы (бухгалтерлык балансының юл коды 1230);

кыска сроклы финанс салулар (1240) – хисап чоры ахырына формалашкан кыска сроклы финанс салулар (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Әйләнеш (түләү) срогы хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаганнар керә, әгәр ул 12 айдан артык булса (бухгалтерлык балансының юл коды 1240);

акча (1250) - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акча (бухгалтерлык балансының юл коды 1250);

агымдагы йөкләмәләр (1500-1530-1540) - түләү срогы хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк булган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Зурлык V бухгалтерлык балансы бүлеге нәтиҗәсенең (бухгалтерлык балансының юл коды 1500), алдагы чор керемнәренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) һәм бәяләү йөкләмәләренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1540) аермасы буларак билгеләнә.

5. Агымдагы ликвидлык коэффициенты ($К_3$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_3 = \frac{\textit{оборотн.активы}(1200)}{\textit{крат.обязательства}(1500-1530)},$$

монда

әйләнештәге активлар (1200) - әйләнештәге активлар (бухгалтерлык балансының юлы коды 1200);

кыска сроклы йөкләмәләр (1500-1530) - түләү срогы хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк булган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Зурлык V бухгалтерлык баланс бүлеге нәтиҗәсенең (бухгалтерлык балансының юл коды 1500) һәм алдагы чор керемнәренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) аермасы буларак билгеләнә.

6. Үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты ($К_4$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_4 = \frac{\textit{собственный капитал}(1300)}{\textit{заемный капитал}(1500+1400-1530)},$$

монда

үз капиталы (1300) – үз капиталы һәм резервлары (бухгалтерлык балансының юл коды 1530);

заем капиталы (1500+1400-1530) – финанс йөкләмәләре. Зурлык, алдагы чор керемнәрен (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) исәпкә алмыйча, кыска сроклы һәм озак сроклы йөкләмәләр (бухгалтерлык балансының юллар коды 1500 һәм 1400) суммасы буларак билгеләнә.

7. Рентабельлек ($К_5$) күрсәткечен исәпләү процедурасы сәүдә һәм башка предприятиеләр өчен аерыла.

8. Сәүдә предприятиеләре өчен рентабельлек күрсәткече, продукция рентабельлегенең финанс коэффициенты нигезендә, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_5 = \frac{\textit{прибыль от продаж}(2200)}{\textit{валовая прибыль}(2100)},$$

монда

сатудан табыш (2200) - продукция сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2200),

тулаем табыш (2100) - тулаем табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2100).

9. Сәүдә булмаган предприятиеләр өчен рентабельлек күрсәткече төп эшчәнлек рентабельлегенең финанс коэффициенты белән туры килә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_5 = \frac{\textit{прибыль от продаж}(2200)}{\textit{выручка}(2110)},$$

монда

сатудан табыш - продукция сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2200);

керем - керем (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2110).

10. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар чик зурлыклар билгеләнә.

11. Алынган зурлык һәм чик зурлыклар нигезендә, һәр зурлык өчен өч категориянең берсе билгеләнә. Күрсәткечләрнең чик зурлыклары һәм күрсәткечләрнең факттагы зурлыкларына бәйле рәвештә категорияне сайлау кагыйдәләре 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица. Күрсәткечләрнең чик зурлыклары һәм күрсәткечләрнең факттагы зурлыкларына бәйле рәвештә категорияне сайлау кагыйдәләре

| Коэффициентлар | 1 категория (күрсәткечнең яхшы зурлыгы) | 2 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек зурлыгы) | 3 категория (күрсәткечнең канәгатьләнмәслек зурлыгы) |
|---|---|---|---|
| $K_1$ | 0,2 дән артык | 0,1 - 0,2 | 0,1 дән ким |
| $K_2$ | 0,8 дән артык | 0,5 - 0,8 | 0,5 тән ким |
| $K_3$ | 2,0 дән артык | 1,0 - 2,0 | 1,0 дән ким |
| $K_4$ | | | |
| сәүдә предприятиеләре | 0,6 дән артык | 0,4 - 0,6 | 0,4 тән ким |
| башка тармак предприятиеләре | 1,0 дән артык | 0,7 - 1,0 | 0,7 дән ким |
| $K_5$ | 0,15 тән артык | 0,0 - 0,15 | 0,0 дән ким (рентабельле булмаган) |

11. Җыелма бәя зурлыгы (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Вес_1 \times Категория_1 + Вес_2 \times Категория_2 + Вес_3 \times Категория_3 + Вес_4 \times Категория_4 + Вес_5 \times Категория_5,$$

монда

Авырлыкi – җыелма бәядә Кi күрсәткеченең авырлыгы, i = 1, 2, 3, 4 яки 5.

Авырлыкларның зурлыклары 2 нче таблицада күрсәтелгән

Категорияi - Кi күрсәткеченең зурлыгы карый торган категория.

Категорияi = 1, 2 яки 3.

2 нче таблица. Җыелма бәяне исәпләгәндә файдаланыла торган күрсәткечләрнең авырлыгы

| Показатель | Вес показателя |
|---|---|
| Абсолют ликвидлык коэффициенты *($K_1$)* | 0,11 |
| Тиз ликвидлык коэффициенты *($K_2$)* | 0,05 |
| Агымдагы ликвидлык коэффициенты *($K_3$)* | 0,42 |
| Үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты *($K_4$)* | 0,21 |
| Рентабельлек күрсәткече *($K_5$)* | 0,21 |

13. Җыелма бәя зурлыгы нигезендә принципалның финанс хәле дәрәҗәсе билгеләнә.

Принципалның финанс хәле түбәндәге дәрәҗәләрнең берсенә ия булырга мөмкин:

финанс хәленең яхшы дәрәҗәсе - әгәр җыелма бәянең зурлыгы 1,05 тән артмаса;

финанс хәленең кангатьләнерлек дәрәҗәсе - әгәр җыелма бәянең зурлыгы 1,05 тән артык булса, ләкин 2,4 дән артмаса;

финанс хәленең канәгатьләнмәслек дәрәҗәсе - әгәр җыелма бәянең зурлыгы 2,4 тән артса.

Башкарма комитетның
2019 елның 5 декабрендәге
6323 номерлы карарына
3 нче кушымта

Муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантия биргәндә бирелгән тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерү, шулай ук муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантия биргәннән соң бирелгән тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Әлеге тәртип муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль гарантия биргәндә (алга таба – гарантия) бирелгән тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерү, шулай ук гарантия биргәннән соң бирелгән тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын контрольдә тоту тәртибен билгели.

2. Принципалның гарантның принципалга карата регресс таләбен үтәүне канәгатьләндерү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү сыйфатында, гарантияне тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешен үтәү белән бәйле рәвештә, түбәндәге тәэмин итү төрләренең берсе яки берничәсе кабул ителергә мөмкин:

1) дәүләт яки муниципаль гарантия;

2) юридик затның поручительлеге;

3) гарантия белән тәэмин ителгән, принципалның кредит буенча кредиторы булмаган кредит оешмасының банк гарантиясе;

4) принципалның яки өченче затның милек залогы.

3. Акча йөкләмәләре буенча Россия Федерациясенең салымнар һәм җыюлар турында законнары нигезендә түләнергә тиешле срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычлары һәм салымнар, җыюлар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булган юридик затларның банк гарантияләре һәм поручительлекләре, шулай ук чиста активлары бәясе бирелгән банк гарантиясенең (поручительнең) өч тапкырга артык күләменнән ким булган, аларга карата бөлгенлек (банкротлык) турында эш буенча производство кузгатылган, реорганизация яки ликвидация процессында булган юридик затлар йөкләмәләр үтәүне тәэмин итү сыйфатында кабул ителми.

4. Гарантия биргәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерү, аны биргәнче, шулай ук гарантия биргәннән соң, бирелгән гарантиянең гамәлдәге срогы эчендә, ел саен 1 июньнән дә соңга калмый, гарантия буенча йөкләмәләр тукталганга кадәр финанс идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне гамәлгә ашыру муниципаль гарантия алу өчен принципал тапшырырга тиешле документлар исемлеге буенча принципал тапшырган документлар һәм муниципаль гарантия бирү турында килешү төзү нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын тикшерү бирелә торган (бирелгән) тәэмин итү таләпләренең гарантия буенча принципалга карата гарантның принципалның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләр үтәүне тәэмин итүнең минималь күләме (суммасы) муниципаль гарантия буенча принципалга карата гарантның принципалның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләр

үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибендә каралган таләпләргә туры килүен билгеләүдән гыйбарәт.

7. Банк гарантиясенең һәм поручительлекнең ышанычлылыгы банкның яки башка кредит оешмасының (алга таба – банк-гарант) һәм поручительнең финанс хәле тотрыклылыгы белән билгеләнә.

8. Әгәр банк-гарант берьюлы түбәндәге таләпләргә туры килсә, банк-гарантның финанс хәле тотрыклы санала һәм банк гарантиясе ышанычлы дип танылa:

1) банк операцияләрен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясе булу;

2) кредит оешмасының «Россия Федерациясе банкларында физик затлар кертемнәрен иминләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларында физик затлар кертемнәрен мәҗбүри иминләштерү системасында катнашуы;

3) гомуми активлар күләменең 50 процентыннан да ким булмаган күләмдә I, II категорияле активлар күләме булу;

4) кредит оешмасының 1 млрд. сумнан да ким булмаган күләмдә үзенең акчалары (капиталы) булу;

5) мәҗбүри нормативлар үтәлеше буенча Россия Федерациясе Үзәк банкының таләбен үтәү (шул исәптән банк гарантиясе бирү белән бәйле кабул ителгән озак вакытлы бурычларны исәпкә алып);

6) соңгы хисап елындагы һәм агымдагы елның соңгы хисап чорындагы эшчәнлек буенча зыян китерелмәү;

7) кредит рейтингының Россия Федерациясе Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгының (Акционерлык җәмгыятенең) «A-(RU)» илкүләм рейтинг буенча шкаласы дәрәҗәсеннән дә ким булмавы яки Россия Федерациясе «Эксперт РА» Рейтинг Агентлыгының Акционерлык җәмгыяте кредит рейтинг агентлыгының «ruA-» илкүләм рейтинг буенча шкаласы дәрәҗәсеннән дә ким булмавы яисә кредит рейтингының «Standard & Poor's» яки «Fitch Ratings» рейтинг агентлыгының «BB-» рейтинг агентлыгы классификациясе буенча дәрәҗәсеннән дә ким булмавы яки «Moody's» рейтинг агентлыгы классификациясе буенча «Ba3» дәрәҗәсеннән дә ким булмавы.

9. Поручительнең финанс хәлен бәяләү принципалның муниципаль бирәмлек муниципаль гарантия биргәндә принципалның финанс хәлен анализлау, шулай ук муниципаль берәмлек муниципаль гарантия биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибенең кушымтасы булган Финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Әгәр поручительнең финанс хәле яхшы яки канәгатьләнерлек дәрәҗәдә бәя алса, шулай ук кредит рейтингы (кредит рейтинглары) булганда, поручитель әгәр кредит рейтингының Россия Федерациясе Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгының (Акционерлык җәмгыятенең) «A-(RU)» илкүләм рейтинг буенча шкаласы дәрәҗәсеннән дә ким булмаса яки Россия Федерациясе «Эксперт РА» Рейтинг Агентлыгының Акционерлык җәмгыяте кредит рейтинг агентлыгының «ruA-» илкүләм рейтинг буенча шкаласы дәрәҗәсеннән дә ким булмаса яисә кредит рейтингының «Standard & Poor's» яки «Fitch Ratings» рейтинг агентлыгының «BB-» рейтинг агентлыгы классификациясе буенча дәрәҗәсеннән дә ким булмаса яки «Moody's» рейтинг агентлыгы классификациясе буенча «Ba3» дәрәҗәсеннән дә ким булмаса, поручительнең финанс хәле тотрыклы һәм поручительлек ышанычлы дип танылa.

11. Принципал яки өченче зат тарафыннан гарантның принципалга карата регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәлрен үтәүгә залогка бирелә торган (бирелгән) милекне бәяләү һәм әлеге милекнең ликвидлык дәрәҗәсен билгеләү Россия

Федерациясе Бюджет кодексының $93^{2}$ статьясындагы 3 пунктның җиденче абзацы нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Финанс идарәсе тиешле бәяләмәне тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне гамәлгә ашырганнан соң 10 көнлек срокта Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшыра.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 5 декабрендәге
6323 номерлы карарына
4 нче кушымта

Муниципаль гарантия биргәндә принципалга карата гарантның принципалның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибе

1. Әлеге тәртип муниципаль гарантия биргәндә, шулай ук муниципаль гарантиянең гамәлдәге срогында принципалга карата гарантның принципалның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләменә (суммасына) таләпләрне билгели.

2. Принципалга карата гарантның принципалның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләме (суммасы) (алга таба – тәэмин итүнең минималь күләме) муниципаль гарантия биргәндә принципалның финанс хәлен анализлау, шулай ук муниципаль бирәмлек муниципаль гарантия биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибенең кушымтасы булган Финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә аның финанс хәленең канәгатьләнерлек дәрәҗәсенә бәйле рәвештә билгеләнә.

3. Тәэмин итүнең минималь күләме түбәндәгеләргә туры килә:

1) принципалның финанс хәле яхшы дәрәҗәдә булганда – муниципаль гарантия суммасының 100 процент дәрәҗәсенә;

2) принципалның финанс хәле канәгатьләнерлек дәрәҗәсеннән югары булмаганда – муниципаль гарантия суммасының 120 процент дәрәҗәсенә.

4. Принципалга карата гарантның принципалның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең гомуми күләме (суммасы) муниципаль гарантия буенча тәэмин итүнең минималь күләменә туры килүен бәяләгәндә:

1) юридик затларның поручительлекләре, банк гарантияләре, муниципаль гарантияләр, алар нинди суммада бирелгән булса, шул суммада исәпкә алына;

2) Бәяләү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 3 статьясының җиденче абзацы нигезендә гамәлгә ашырыла торган залогка бирелүче (бирелгән) милекнең базар бәясенә, 0,7 коэффициентын кулланып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова